**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул.Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт,
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

2024 елның 15 феврале 89 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре "муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 2023 елның 13 декабрендәге 82 карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында" 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре "муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 2023 елның 13 декабрендәге 82 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре "муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

28 нче бүлекнең 22 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләрне билгеләү һәм түләү турындагы мәгълүмат "Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа" дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла, "Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа" дәүләт мәгълүмат системасында әлеге мәгълүматны урнаштыру (алу) "Дәүләт социаль ярдәме турында" 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык- Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Лаеш шәһәре Советы рәисе** **И.Ф.Зарипов**